ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27.05. Баулы шәһәре № 151

Баулы муниципаль районы
территориясендә муниципаль контроль
төрләре һәм аларны гамәлгә ашыру
өчен җаваплы кешеләр исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон (2019 елның 1 маендагы редакциядә), «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елныж 26 декабрендә кабул ителгән 294нче санлы федераль закон, Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 20 маенда кабул ителгән __ номерлы “Муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибе турында” карары нигезендә һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы кешеләр исемлеге (1нче кушымта);

Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге (2нче кушымта).

2. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасары Э. И. Галимовка йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров